ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында»**;

2) 1 статьяда «уздыру тәртибен һәм эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларына (алга таба – норматив хокукый актлар)» сүзләрен «, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Президенты указларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларының (алга таба – норматив хокукый актлар) факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм норматив хокукый актларга» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяда:

а) исемендә «һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Норматив хокукый актлар проектларына әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла торган җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиеш, моңа түбәндәгеләр керми:

1) региональ салымнарны, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

2) бюджетка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

3) түбәндәге норматив хокукый актлар проектлары:

а) продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) җайга салына торган бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сату өстәмәләре (өстәмә бәяләр) өлкәсендә бәя кую тәртибен билгели торган федераль законнар нигезендә продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сату өстәмәләре (өстәмә бәяләр) билгеләүче, үзгәртүче, юкка чыгаручы;

б) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булу чорына әзерләнгән.»;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $3^{1}$ статья өстәргә:

«$3^{1}$ статья. **Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибе**

1. Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салучы орган тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә уздырыла.

2. Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру турындагы җыелма хисапта күрсәтелгән җайга салу максатларына ирешүне анализлау, норматив хокукый актлар кабул итүнең факттагы уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен билгеләү һәм бәяләү, шулай ук аларда эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген алып баруны нигезсез кыенлаштыра торган яисә Татарстан Республикасы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнарының барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

3. Норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү турында бәяләмә вәкаләтле орган тарафыннан җайга салучы органнан килгән норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү хакындагы хисап нигезендә әзерләнә.

4. Норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәдә күрсәтелгән нәтиҗәләр вәкаләтле орган тарафыннан норматив хокукый

актка үзгәрешләр кертү турында яисә аны юкка чыгару хакында тәкъдимнәр әзерләү өчен нигез булырга мөмкин.»;

5) 4 статьяның 1 өлешендә татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 64-ТРЗ